**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 28 май

№ 384

г. Казань

2015 елда Казан шәһәрендә Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү чаралары планын раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында» 2014 ел, 30 май, 365 нче карары белән расланган Яшь геолог- ларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2015 елда Казан шәһәрендә Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү чаралары планын расларга (алга таба – План).

2. Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын (алга таба – олимпиада) әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетына 2015 елда олимпиаданы әзерләү һәм үткәрү чараларының эреләтелгән смета исәп-хисабын расларга.

3. «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыятенең, «Нефтеконсорциум» ябык акционерлар җәмгыятенең, кече нефть компанияләренең, «Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты» федераль дәүләт унитар предприятиесенең яшь геологларның мәктәп командаларын әзерләүдә һәм олимпиаданы үткәрүдә бар яктан ярдәм күрсәтү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Киләчәк» – «Будущее» 2010-2015 елларга Татарстан Республикасында Мәгарифне үстерү стратегиясен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1174 нче карары белән расланган «Киләчәк» – «Будущее» 2010-2015 елларга Татарстан Республикасында Мәгарифне үстерү стратегиясен тормышка ашыруга каралган акча исәбеннән олимпиаданы әзерләү һәм үткәрү буенча чыгымнарны 2015 елда финанслауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына План чараларын билгеләнгән вакытларда үтәүне тәэмин итәргә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына һәм олимпиаданы әзерләү һәм үткәрүдә катнашучы оешмаларга тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына олимпиаданы үткәрүне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

7. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча җир асты байлыкларыннан файдалану идарәсенә олимпиаданы әзерләү һәм үткәрү комитетына аны үткәрүдә булышлык күрсәтүне;

«Россия геология җәмгыяте» иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә олимпиаданы оештыруда һәм үткәрүдә булышлык күрсәтүне;

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институтына олимпиадага фәнни-методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыруны;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына:

оештыру комитетына олимпиаданы әзерләүдә һәм үткәрүдә булышлык күрсәтүне;

олимпиада үткәрелгән объектларда һәм анда катнашучылар яшәгән урыннарда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итүне;

олимпиада үткәрелә торган объектларны һәм анда катнашучылар яшәячәк урыннарны олимпиада үткәрүгә әзерләүне.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын үткәрү турында» 2014 ел, 30 май, 365 нче карары белән расланган Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан Н.Г.Мәһдиевны чыгарырга;

Әкъдәсов Эдуард Илдар улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институтының өлкән укытучысы (килешү буенча)»;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Назыйров Алмас Әмин улын | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрын |
| Мөхәммәтов Илдар Ринат улын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын |
| Зорина Светлана Олеговнаны | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем |

учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты доцентын (килешү буенча).

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\384.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 28 май, 384 нче карары
белән расланды

**2015 елда Казан шәһәрендә Яшь геологларның республика ачык кыр олимпиадасын әзерләү һәм үткәрү чаралары планы**

| Т/с | Чараның исеме | Җаваплы үтәүчеләр | Үтәшүчеләр | Үтәү вакытлары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | «Костер» лагерында мәктәп укучылары өчен профиль сменасы, Бөреле поселогы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ техноло-гияләре институты (килешү буенча) | апрель – май 2015 ел |
| 2 | Татарстан Республикасы яшь геологлары җыелма командасына кандидатларны башлангыч сайлау өчен тест үткәрү | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ техно-логияләре институты (килешү буенча) | | апрель – май 2015 ел |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Татарстан Республикасы яшь геологлары җыелма командасына кандидатлар белән 3 – 5 көнлек геологик маршрутлар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ техноло-гияләре институты (килешү буенча) | май – июнь 2015 ел |
| 4 | Яшь геологларның II республика ачык кыр олимпиадасы (алга таба – олимпиада) штабын һәм хөкем-дарлар коллегиясен раслау | Олимпиаданы әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ техноло-гияләре институты (килешү буенча) | 28.05.2015 |
| 5 | Югары һөнәр белеме бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном белем учреждениесе, югары һөнәр белеме бирүче «Әлмәт дәүләт нефть институты» дәүләт бюджет белем учреж-дениесе каршындагы мәктәп факультетларының, олимпиадада катнашу турында белдергән белем | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан (Идел буе) федераль универ-ситеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты (килешү буенча) | Оештыру комитеты | 31.05.2015 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | бирү оешмалары базасындагы түгәрәкләрнең уку-укыту процесс-сларын оештыру | | | |
| 6 | Ярышларның кыр маршрутларын эшләү һәм оештыру | Оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты (килешү буенча) | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты (килешү буенча) | 31.05.2015 |
| 7 | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесеннән волонтерлар сайлап алу һәм әзерләү | Оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесе (килешү буенча) | Оештыру комитеты | 31.05.2015 |
| 8 | Минералларның, тау токымнарының уку-укыту коллекцияләрен, палеонтология коллекциясен, киселешләр төзү буенча геология карталарын әзерләү | Оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесе (килешү буенча) | | 31.05.2015 |
| 9 | Олимпиадада катнашучыларны ярышлар үткәрү өчен кирәкле приборлар һәм аппаратура белән тәэмин итү | Оештыру комитеты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәр белеме бирүче федераль дәүләт автоном белем учреждениесе (килешү буенча) | «Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты» федераль дәүләт унитар предприятиесе (килешү | 23.06.2015 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | буенча), Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы | |
| 10 | Катнашучыларны олимпиада үткәрү урыннарында кабул итүне, урнаштыруны һәм аларның яшәвен оештыру | Оештыру комитеты | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) | 31.05.2015 |
| 11 | Олимпиада үткәрүне мәгълүмати-технологик яктан IT-инфраструктура объектлары белән тәэмин итү, шул исәптән олимпиада штабын оештыру, оештыру техникасы һәм компьютерлар белән комплектлау | «Татарстан Республикасы Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 27.06.2015 |
| 12 | Олимпиаданың мәдәни һәм спорт программаларын оештыру, шул исәптән:<br>олимпиаданы ачу һәм ябу сцена-рийларын эшләү һәм аларны тормышка ашыру;<br>олимпиада үткәрелгән көннәрдә мәдәни-ял итү программасын төзү һәм тормышка ашыру | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | Оештыру комитеты | 27.06.2015 – 14.07.2015 |
| 13 | Комплекслы көчләр нарядларының патруль маршрутларын олимпиа- | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы | Оештыру комитеты | 27.06.2015 –14.07.2015 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | дада катнашучылар яшәгән һәм чаралар үткәрелгән урыннар янына якынайту | (килешү буенча) | | |
| 14 | Олимпиадада катнашучылар яшәгән һәм ярышлар үткәрелгән урыннарда янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итү | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | Оештыру комитеты | 27.06.2015 –14.07.2015 |
| 15 | Олимпиада үткәрүне медицина ягыннан тәэмин итү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | Оештыру комитеты | 27.06.2015 –14.07.2015 |
| 16 | Олимпиадада катнашучыларны һәм кунакларны каршылауны һәм аларны яшәү урынына кадәр транспортта алып баруны оештыру | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | Оештыру комитеты | 27.06.2015 |
| 17 | Олимпиаданы гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итү | «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы | Оештыру комитеты | 27.06.2015 –14.07.2015 |